СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон (8552) 70-00-33, факс 70-12-61, tukay.rt@tatar.ru

30.07.2024 № 12/4

На №__________ от______________

# КАРАР

## «Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2007 елның 27 апрелендәге 13/8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2007 елның 27 апрелендәге 13/8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Күпфатирлы йорттагы урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру тәмамлангач, мөрәҗәгать итүче әлеге кодексның 23 статьясы 9 өлешендә каралган ысул белән килештерүне гамәлгә ашыручы органга күрсәтелгән эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамә җибәрә. Бинаны яңадан планлаштырган очракта, мондый хәбәрнамәгә мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән яңадан планлаштырылган бинаның техник планы теркәп бирелә. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә яңа урыннар барлыкка килгән очракта, бинаны яңадан планлаштыруның тәмамлануы турында хәбәрнамәдә мөрәҗәгать итүченең күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алуга дәүләт пошлинасын түләве турындагы белешмәләр күрсәтелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары

Р.И. Закиров